Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№32 (125)

13 ноябрь 2014 ел




Күз – уңыш җыяр чак. Шуңа да яшь иҗатчыларның уңышларын нәкъ менә көзен барлау гаҗәп түгел. Күптән түгел Әлмәт татар дәүләт драма театры бинасында С.Сөләйманова исемендәге премия һәм стипендияләрне тапшыру тантанасы булып узды. Җиңүчеләр арасында КФУ студентлары да бар иде. Әлеге дәрәҗәле стипендиягә Математика һәм механика институтының 3 курс студенты, «Darelfөnyn»нең актив хәбәрчесе, хезмәттәшебез Илмир Вәлиев та иреште. Сәхифәбезнең бүгенге кунагы да нәкъ менә ул!

# «Вакытны дөрес бүлә белү мөһим!»

Влад Михневский фотосы

● Фән дөньясында

# Чит ил галимнәре исламны өйрәнә

**Себастьян ЦВИКЛИНСКИ,** фәлсәфә фәннәре докторы, Берлин әдәбият һәм мәдәниятләр институтының штаттагы хезмәткәре

Гадәт буенча, мин үткән атнада тагын Казанга килдем. Һәр көздәге кебек, быел да Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты кафедрасы тарафыннан оештырылган «Күпмәдәниятле дөньяда Ислам» конференциясендә катнаштым.

Конференцияне оештыручылар быел да чит илләрдән, Рәсәйнең төрле төбәкләреннән танылган галимнәрне чакырганнар. Чыгышлар бик кызыклы һәм гадәти булмаган темаларга багышланган иде.



Мисал итеп, минем өчен бик кызыклы булган бер генә темага тукталасым килә: ислам динен кабул иткән руслар. Милләте буенча – рус, дине буенча мөселман булган «Мусульманка» журналының редколлегия әгъзасы, Мәскәүдән килгән Анастасия Ежова тыңлаучыларга, үз тәҗрибәсеннән чыгып, рус мөселманнарының тормыш итү рәвешен сурәтләп бирде. Голландиядән студент Ева Рогаар исламны кабул иткән руслар белән үткәргән әңгәмәләр вакытында туплаган тәэсирләре белән уртаклашты.

Конференцияне оештыручыларның берсе Азат Ахунов исә, татар имамнарының рус мөселманнары турындагы фикерләрен бәян итте. Имамнарның күбесе рус-неофитлар турында тәнкыйди фикер йөртә, чөнки исламны яңадан кабул иткән кешеләр еш кына ислам диненең кануннарын сүзгә-сүз үтәргә тырышалар, ә бу күп вакыт радикализм куркынычын тудыра икән. Моннан тыш, рус мөселманнарның мәчетләргә күпләп килүе татар мөселманнарның тел ягыннан ассимиляцияләшүенә китерергә мөмкин.

Конференциянең әһәмияте дә шунда: биредә яңгыраган һәр сүз бик зур мәгънәгә ия, фикерләр төрле бәхәскә китерергә мөмкин. Интернеттагы ислам турында төрле сәхифәләр, Грузиядәге социаль челтәрләрдә исламофобия, кебек темалар хәзерге заманда яшәүчеләр өчен мөһим дә, кызыклы да, чөнки алар безнең тормышка турыдан-туры карыйлар.

Конференциянең тагын бер яхшы сыйфаты – чараның дустанә атмосферада узуы. Гомумән алганда, конференция узган еллардагы кебек үк уңышлы үтте. Оештыручыларның һәркайсына да зур рәхмәт! Рәхмәт, Казан! Чакырсаң, тагын килербез!

● Белем баскычлары



Җитмеш биш яшьлек Тәүзих абыйның компьютерда миннән дә яхшырак эшли белүеннән бераз уңайсызланып куйдым. Тукта әле, мәкаләмне дөрес башламадым, бугай. Барысын да тәртип буенча, тәфсилләбрәк сөйлим...

# Фонетика серләре

**Алсу СӘЛАХОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Иң беренче чиратта, сезнең күңел кылларын кытыклап алам: дүртенче ноябрь көнне татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы доценты Гөлфия апа Һадиева җитәкчелегендә без, беренче курс журналистика һәм икенче курс кытай, инглиз белгечлеге студентлары, «Татар теленең экспериментал фонетикасы» фәнни-тикшеренү лабораториясендә кунакта булдык. Белгәнегезчә, В.А.Богородицкий Россиядә иң беренче экспериментал фонетика лабораториясен Казанда ачып, татар авазларын өйрәнү буенча искиткеч тикшерүләр үткәрә. Бөек галим эшләгән лаборатория нигндидер тылсымлы көчкә ия сыман тоелды миңа.

Безне монда шушы лабораториянең җитәкчесе, доцент, филология фәннәре кандидаты, машина тәрҗемәсен һәм кибернетиканы гомере буе өйрәнгән Тәүзих Ибраһимович Ибраһимов каршы алды. Ул үзенең тыныч тавышы, экспериментал фонетика өлкәсендәге тирән белеме белән безне бер минут эчендә әсир итте.

Дөресен генә әйткәндә, без фонетиканың нинди көчле, әһәмиятле фән икәнлеген аңлап җиткермибез бугай. 1960-70нче еллардагы фонетика фәне, нигездә, алфавитны һәм орфографияне күбрәк өйрәнсә, хәзер исә ул роботларга тәэсир итүне, төрледән-төрле авыруларга ярдәм итү юлларын (шулардан берсе – логопедия), синтезаторларның (сөйләм төзүче машиналарның) техник мөмкинлекләрен киңәйтүне дә өйрәнә. Соңгы әйтелгәне аеруча зур әһәмияткә ия, чөнки синтезатор электрон версиядәге текстларны укый. Ә бу программа күзләре начар күргән кешеләр өчен бик файдалы.

Килүгә, йомшак тавышы белән үзенә җәлеп иткән Тәүзих абый тора-бара безне икеләтә шаккатырды. Компьютерда бер программа артыннан икенчесен оста гына ачып, төрле фонеманың көчен, спектрын, озынлыгын әйтеп бирде. Берничә бәхетле кызның тавыш үзенчәлекләрен дә тикшереп күрсәтте ул хәтта.

Бу очрашуда алган мәгълүматлар тел белгечләре өчен, һичшиксез, зур әһәмияткә ия, ләкин тел белән артык мавыкмаганнарга да бик кызыклы тоелыр иде, минемчә. Шуңа күрә галимнәребез эшләп чыгарган «Письменный корпус татарского языка» сайтына (http://corpus.tatfolk.ru/) керү аларга да файдалы булачак. Монда сез 116 миллион сүзнең язылышын, әйтелешен һәм ниндирәк текстларда урнашуын күрә алачаксыз. Алда әйтелгән сүзләремне йомгаклап, мәкаләмне Тәүзих абыйның синтезаторында яңгыраган, кечкенә чагында әнисе көйләгән мөнәҗәт белән тәмамлыйсым килә:

*Укыганның тормышы мул,*
*Укыганның йөзендә нур!*
*Уку, язу белгән адәм*
*Беркайчан да булмас ул хур.*

***P.S.:*** Үзегезнең нинди дә булса аудиториягә тәэсир итү көчегезне арттырасыгыз килә икән, һичшиксез, сөйләмегезгә игътибарлы булыгыз. Һәм һәрвакыт сөйләмегезне камилләштерү өстендә эшләгез. Кыскасы, укыйк, дуслар, белем алыйк!

● Туган тел сагында

# Безнең фикер!

**Алинә СОЛТАНГЫЙЛЬДИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Шушы көннәрдә «Республика дебатов» Татарстан белем бирү-дискуссия үзәгендә күптән көтелгән вакыйга – беренче тапкыр парламент дебатлары буенча татарча «Безнең фикер» турниры уздырылды.

Татар телендә парламент дебатлары тәҗрибәсен үзләштерергә теләүчеләр байтак булып чыкты. Югары уку йортлары (КФУ, Россия дәүләт хокук университеты) студентлары белән беррәттән, үз фикерләрен җиткерергә, туган мәктәп-гимназияләренең белем дәрәҗәсен күрсәтергә өлкән сыйныф укучылары да килгән иде.



Мондый чарада беренче тапкыр гына катнашканлыктан, күбесендә дулкынлану сизелә иде. Уен һәм турнир кагыйдәләрен бик яхшы белмәсәләр дә, аларның үз фикерләре бар, үз командасы позициясен һәркайсы кыю яклады. Үз фикерләрен төгәлрәк җиткерү өчен, рус сүзләре дә «кыстырылды». Бу мондый чараларны татар телендә ешрак үткәрергә кирәклеген дәлилли. «Дебатларның максаты – сәләтле яшьләрне ачыклау, аналитик уйлауны, ораторлык осталыгын, катнашучыларның җитәкчелек һәм коммуникатив компетентлыгын үстерү, актив иҗтимагый инициатива һәм гражданлык позициясе формалаштыру, халык алдында чыгыш ясау культурасын булдыру. Чараны татарча үткәрергә карар кылдык. Бу Татарстан Республикасының сәләтле татар яшьләрен ачыкларга һәм татар телен, мәдәниятен популярлаштырырга ярдәм итәчәк», – диде хакимнәр коллегиясен җитәкләгән, татар телендә мондый турнирны ел саен үткәрү тәкъдимен хуплаган Аммар-Әл-Әнси.

Катнашучылар һәр этапта бирелгән рольгә шулкадәр кереп киттеләр, хәтта дебатларның «Россия 1» каналында бара торган «Поединок» тапшыруына охшап калган мизгелләре дә булды.

Яшь «Премьер-министрлар» һәм «Оппозиция лидерлары» теге яки бу законнарны кабул итү-итмәүне яклаганда, ишек артында укучыларының һәр сүзен тотып алырга тырышкан укытучы-җанатарлар ут йотты. Казанның 71нче мәктәбе татар теле укытучысы, милли мәгариф буенча директор урынбасары Рамилә Кашапова үз фикерләре белән бүлешеп: «Мин үз укучыларым – «Ният» командасына көч биреп



тору өчен килдем. Беренче раундта, безнекеләр хакимият, тәмәке тартучылар яклы булып уйнаганда, авырга туры килде. Чөнки мәктәптә бу күренешкә тискәре караш тәрбиялибез бит», – диде. Шулай булуга карамастан, һәр команда үзен хакимият һәм оппозиция ролендә сыный алды.

Җиңүчеләрне бүләкләү өчен, мәртәбәле кунаклар чакырылган иде. Беренче урынга КФУның Идарә, икътисад һәм финанас институтыннан «Тәҗрибә туплаучылар» командасы (И.Вәлиуллин һәм Г.Госәмова) лаек булды! Турнирның иң яхшы спикеры итеп, «Хакыйкать» командасыннан З.Шәгаввәлиева билгеләнде. Котлыйбыз! Алга таба уңышлар һәм зурдан-зур үрләр яулауларын телибез!

● Юбиляр

Укытучы өчен укучыларының рәхмәтеннән, игътибарыннан һәм хөрмәтеннән дә зуррак бәхет бармы икән? Бигрәк тә укучыларның, берничә дистә еллар вакыт узганнан соң да элемтәләрне өзмичә, остазлары белән аралашып торуы, үзара ярдәмләшеп яшәве – ихтирам хисен дәлилли торган фактор. Шушы көннәрдә филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты доценты, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, К.Насыйри исемендәге премия лауреаты, Россия Федерациясе югары уку йортларының атказанган хезмәткәре Рәсимә Равил кызы Шәмсетдинова үзенең күркәм юбилеен каршылый. Бу уңайдан аны котлап, КДУ каршындагы академик колледжның 1996 елгы чыгарылыш сыйныфы укучылары остазлары турындагы фикерләре, хатирәләре белән бүлеште.

# «Киләчәккә этәргеч биргән остазыбыз!»

● *Ләззәт Хәйдәров, Татарстан Республикасы Президент аппараты хезмәткәре:*

«Рәсимә Равиловна белән без 20 ел буе бергә. Нәкъ шуның кадәр без аны беләбез, яратабыз, хөрмәт итәбез. Хәзер дә, инде үзебез гаиләле, балалы булгач та, төпле киңәш кирәк булса, берәр сорауга җавап таба алмасак яки, киресенчә, сөенечебез белән уртаклашасыбыз килсә, без аңа мөрәҗәгать итәбез. Рәсимә апа 1994-96 елларда безнең сыйныф житәкчебез иде. Без 10-11 сыйныфларны КДУ каршындагы академик колледжның «Я» классында укыдык, «Яшки» дип йөртәләр иде. Безнең сыйныфта татар теленә, татар әдәбиятына өстенлек бирелә иде. Шулай ук без төрек телен дә өйрәндек, Лена апа гарәп телен укытты. Сыйныфта без бары 9 гына кеше идек. Бик дус һәм тату булдык. Хәзер дә һәрдаим элемтәдә торабыз, гаиләләр белән йөрешәбез. Әлеге татулык, туганлык хисен сеңдергән кеше ул – Рәсимә апа.

Минем өчен Рәсимә апа – идеаль татар хатын-кызы. Ул мөлаем, тыныч, чибәр, зыялы, затлы. Безне һәрвакыт яхшылыкка, алга таба барырга, югарыга менәргә өндәде, этәрде. Ул безне рухи яктан бик нык баетты. Аның киңәше һаман да истә: университет белән генә чикләнеп калмыйча, аспирантурага керергә тәкъдим итте. Аның киңәше һәм рухи ярдәме белән, мин дә аспирантура бетердем.

Рәсимә апаның зур байлыгы – гаиләсе. Аңа гаилә тынычлыгы, гаилә иминлеге, саулык-сәламәтлек телибез. Ул һәрвакыт тыныч һәм сабыр. Аның әлеге тынычлыгы җуелмасын иде. Һәрдаим күңелле, матур мәшәкатьләр өстәлеп, гаиләсе, энергиясе тулыланып торсын!»

● *Розанна Мингарипова, хуҗабикә, 4 бала әнисе:*

«Рәсимә Равиловна минем күңелемә бик таләпчән һәм кешелекле шәхес буларак кереп калды. Аны искә төшергәндә, һәрвакыт җанга җылы булып китә. Колледжга беренче тапкыр килгәндә, безне, класс җитәкчебез буларак, Рәсимә Равиловна, шулай ук Лена Кәлимуллловна, Резеда Кадыйровна һәм тагын бик яхшы укытучылар каршы алды. Ул вакытта безгә нибары 15 яшь, ни теләгәнебезне, нәрсәгә омтылганыбызны аңламый торган яшүсмерләр идек. Тормышыбызның нәкъ менә шундый мөһим һәм хәлиткеч вакытында без искиткеч яхшы мөгаллимнәр кулына эләктек. Алар безгә баштан ук хөрмәт һәм мәхәббәт белән карадылар. Колледжда һәрвакыт үзебезгә карата ихтирам, җылылык, мәхәббәт хисе һәм ышану тоя идек. Миңа калса, бу бик мөһим. Укытучылар безгә «Сез» дип дәшә, барлык шелтәләр дә яхшылык теләп әйтелә һәм, иң мөһиме, безгә, сәләтләребезгә ышаналар, ихтирам итәләр иде. Шуның нәтиҗәсендә, беренче чиратта, үз-үзебезгә ышанырга, үзебезне ихтирам итәргә өйрәндек. Безгә һәрдаим: «Сез – интеллигенция! Сез – асылташлар! Сез барысын да беләсез һәм эшли аласыз», – дип әйтәләр иде. Мондый сүзләрдән соң, үзеңне, чын мәгънәсендә, зыялы дип хис итә башлыйсың. Менә шул вакытта безгә салынган база, эчке терәк минутында ук беленмәсә дә, киләчәккә этәргеч булган икән. Без аны гомеребез буе тоябыз һәм аннан файдаланабыз. Менә шуның өчен мин остазларыма бик рәхмәтлемен!

Рәсимә апа безгә һәрвакыт рухи яктан төпле киңәшләре белән ярдәм итә иде. Инде безгә уку йортында укуыбыз вакытта да, без колледжга, Рәсимә апабыз янына килә, күрешә, аралаша идек. Миңа калса, ул бик оптимист кеше. Аның әлеге оптимистлыгы беркайчан да югалмасын, һәрвакыт укучыларының рәхмәтен, җылысын тоеп яшәсен иде!»



■ Рәсимә Шәмсетдинова хезмәттәшләре һәм укучылары белән. Казан, 1996 ел.

● *Шамил Вәлиев, Казанның Яңа Савин һәм Авиатөзелеш районнары администрациясендә физкультура һәм спорт бүлеге җитәкчесе:*

«Рәсимә Равиловнаны бөтен җирдә беләләр һәм хөрмәт итәләр. Аның янында без дә тәрбиялерәк, яхшырак булырга тырыша идек. Хәзерге вакытта ул дәрәҗәдәге зыялы һәм нәзакәтле хатын-кызлар бик сирәк. Өченче буында гына чын зыялы буласың, дигән гыйбарә бар, ул тулысы белән Рәсимә Равиловнага туры киләдер дип уйлыйм. Мин аны морзаларга тиңләр идем. Аның үзенә бер төрле бөек тынычлыгы, татарларга хас миллилеге бар. Алар, Лена Кәлимуллловна белән бергә, колледж өчен бик күп эшләделәр, миллилек факторын алга чыгару өчен күп көч куйдылар.

Рәсимә Равиловна өйрәткән әйберләрнең барысы истә дә түгелдер, кайберләре инде онытылгандыр да, ул үзенең фәне аркылы безне тормышка өйрәтте. Ул үткәргән дәресләрне хәзер дә искә алам, алар бик күңелле уза иде. Хәзерге көн һәм ул вакытлар өчен дә бик гаҗәп нәрсә: без дәресләр вакытында чәй эчә идек. Шундый җылы һәм өй атмосферасында уза иде дәресләребез. Рәсимә апа бөтен җирдә тәртип ярата иде, шуңа күрә уку дәверендә гадәттән тыш хәлләрне, аның әрләүләрен, тавыш күтәргәнен хәтерләмим. Рәсимә апа гомере буе башкалар өчен янып-көеп яшәде. Мин аңа хәзер үзе өчен, үз рәхәте өчен яшәвен теләр идем. Ул һәрвакытта да төпле, акыллы, һәркем өчен дә үрнәк булды һәм булачак!»

● Җиңүләр һәм табышлар

# Ялкынлы бәйрәм

**Айзилә БАТЫРХАНОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Ә сез беләсезме, безнең яраткан университетыбызның җир шарында гына түгел, хәтта күктәге алиһәләр, илаһи көчләр дә белә икән!

6 ноябрь, гадәттәгечә, шаулап-гөрләп башланып китте. Ә менә безнең институтның Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә белем алучы беренче курс студентларының иртәсе җыр-биюле репетициядән башланды. Алар институтыбызның атаклы профессорлары, галим-галимәләре һәм югары курс студентлары алдында иҗади имтихан тотып, чын студент исеменә лаек булачаклар.

Актлар залына кереп утыру белән, тамашачылар күзгә-күз тарих белән очраштылар, безнең эрага кадәрге Греция мохитенә килеп эләктеләр. Зевсның улы, сугыш алласы Арес фикерләвенчә, бүгенге көн өчен техник фәннәр әһәмиятлерәк. Аңа каршы Афина югары культурага ия булган, һәр сүзнең тәмен, хасиятен белеп сөйләүче филологлар, ораторлар үстерү ягында. Алиһәләр нәкъ менә шундый ораторларны әзерли торган уку йортларын эзләгәндә, КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына тап булалар. Беренче курс студентлары белән танышырга, аларны филологларга, бөек ораторларга хас булган күркәм сыйфатларга өйрәтү өчен, алиһәләр үзләренең филиярдәмчеләрен, ягъни кураторларны «җиргә» төшерәләр. Менә шуннан инде чын бәйрәм башланып китте.

Узган еллардан аермалы буларак, быелгы беренче курслар бәйрәме башкачарак, ягъни конкурс формасында үтте. Дүрт төркем үзара беренчелек өчен көч сынашты.

Бәяләргә, җюри әгъзалары төркемнәрнең бердәмлегенә, чыгышның темасын тулысынча ачып бирүгә, оригинальлеккә, креативлыкка игътибар итте. Һәр дүрт төркем дә нык әзерләнгән, чыгышлар үзенчәлекле һәм кабатланмас булды. Татар филологиясендә елдан-ел бик тә сәләтле, иҗади яктан бай студентлар килә. Һәр төркемнең шаян һәм тапкыр студентларыннан торган КВН командасы да оешкан.





Хөрмәтле җюри әгъзасы – ТРның халык артисты, режиссер, «Мизгел» яшьләр театрының җитәкчесе М.Җаббаров әйткәнчә: «Бу чын яшьлек бәйрәме булды. Соңгы елларда беренче курслар бәйрәменең ялкыны берникадәр сүрелеп барса, быел ул дәртләнеп яна башлады».

Шулай итеп, җюри әгъзалары билгеләвенчә, 3нче урынны татар теле, әдәбияты һәм журналистика төркеме белән татар теле, әдәбияты, тәрҗемә (чит телне тирәнтен өйрәнүче) төркемнәр бүлеште. Икенче урынны татар теле, әдәбияты һәм инглиз теле төркеме алды. Ә менә беренчелеккә кытай һәм төрек телләрен тирәнтен өйрәнүче 10.2-405 төркеме лаек булды. Алга таба бу студентларны университетыбыз куләмендә үткәрелә торган чараларда, конкурс-фестивальләрдә дә күрербез дип өметләнәбез.

• Таныш бул!

# «Вакытны дөрес бүлә белү мөһим!»



**Ләйсән ИСХАКОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

### Математик та, лирик та

Минкечкенәдән төгәл һәм гуманитар фәннәрне бертигез дәрәҗәдә белүчеләргә сокланам. Илмир да шундыйлардан. Кәкресызыклы интегралларны исәпләү дә, газетага мәкалә язу да аңа бертөсле җиңел бирелә. Шулай да, югары уку йортына кергәндә, мехматны сайлаган Илмир. Ни өчен, дигән сорауга: «Мәктәптә укыганда ук төгәллекне яраттым. Хәзер дә төгәллек яшәешемнең төп кагыйдәсе булып тора. Нәкъ менә шуңа күрәдер дә математика юнәлешен сайладым. Ләкин мәктәп елларында гуманитар фәннәрне дә үз иттем», – дип җавап бирде егет. Үз итүе дә югары дәрәҗәдә булган: татар әдәбияты буенча республика олимпиадасында призлы урын яулаган ул. Мәктәптә укыган вакытта, «Алтын каләм», «Илһамлы каләм», «Медиапокорение» кебек республика, бөтенроссия фестивальләрендә, иҗади конкурсларда һәрдаим катнашып, зур җиңүләргә ирешүе дә – әдәбиятны үз итү нәтиҗәсе. Бу уңышлары өчен Илмир үзен яраткан остазы – Яңа Чишмә районы Зирекле лицееның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәния Зариповага бурычлы дип саный. Бүген исә студент егет Математика һәм механика институтында ел да уздырылып килә торган фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша. Әле күптән түгел булып узган «Лобачевский укулары» Бөтенроссия конференциясендә чыгыш ясап, ул җиңүче дипломына лаек булды. Шулай да Илмир иҗатка да вакыт таба. Газетабыз битләрендә аның материаллары бик еш басыла. «Каләм чарларга яраткан газетам, яраткан коллективым бар!» – дип сөенеп яши ул. С.Сөләйманова исемендәге стипендиягә дә егет газетага материаллар язу һәм Әлмәттәге «Хәзинә» газетасы белән хезмәттәшлек итүе нәтиҗәсендә ирешкән. Үзен реалист-романтик дип санаучы студент бер урында тик утырырга һич кенә дә яратмый.

### Спорт – көндәлек механизм

Фән, иҗат белән шөгыльләнүдән тыш, Илмир спортка да вакыт таба. Мәктәп чорыннан ук волейбол белән кызыксына. Берничә ел рәттән туган лицееның җыелма командасы өчен уйнаган. КФУда укый башлагач та, спортчы егет институтның җыелма командасы составында чыгыш ясый. Чаңгы эстафеталарында катнашып, җиңүләр яулый. Бүген исә Илмир баскетбол белән мавыга. Моннан бер ел элек узган Универсиада вакытында егет Гимнастика үзәгендә волонтер булган. Шуннан бирле гимнастикага да кызыксынуы уянган. Киләчәктә үзләштерәсе килгән спорт төре дә шул икән.

### Авылда шәһәрчә яшибез!

Студент тормышының тагын бер аерылгысыз өлеше – тулай торак. Менә инде өченче ел рәттән Илмир Универсиада авылында яши. Үзе әйткәндәй, иң яхшы комендант А.Р.Чакмак һәм иң яхшы педагог-оештыручы Р.Р.Хаҗиева җитәкләгән бишенче йортта. Егет – тулай торакта да иң актив студентларның берсе. Бер карасаң, КФУ студентлары арасында үткәрелә торган «Без сәламәт яшәү рәвеше өчен» мәдәни-спорт чарасында катнаша, икенче карасаң, Сәламәтлек көненә багышланган бәйрәмдә актив чыгыш ясый, өченче карасаң, «Студентлар көзе»ндә сәләтен күрсәтә. Кыскасы, Универсиада авылында уздырыла торган бер генә чарадан да читтә калмаска тырыша ул. Студент егет фикеренчә, Универсиада авылы студентларга аралашу, күңел ачу, яңа дуслар табу өчен менә дигән мәйдан булып тора.

### Киләчәк турында

Илмир өчен уку һәм иҗтимагый тормыш – берберсеннән башка яши алмый торган ике юнәлеш. Студент егет һәр эшкә җаваплы һәм шул ук вакытта иҗади якын килергә кирәк, дигән фикер яклы. Моның өчен, әлбәттә, вакытны дөрес бүлә белергә кирәк. Илмир, моны истә тотып, иртәгә эшләнергә тиешле эшләрне кичтән үк планлаштырып куя һәм нәтиҗәдә барысына да өлгерә.

«Киләчәктә үзеңне кем итеп күрәсең?» дигән сорауга Илмир тыйнак кына: «Алдан әйтүе кыен. Ләкин кем генә булсам да, иң беренче чиратта, кеше булып калырга телим!» – дип җавап кайтарды. Шулай да чынга ашырасы хыяллары күп егетнең. Шуларның берсе – дөнья буйлап сәяхәт итү. Бик тиздән бу хыялының тормышка ашасына зур ышаныч белән яши ул. Моңа «Darelfønyn» редакциясе дә ышана. Хәерле уй-теләкләреңне чынбарлыкка әйләндерү юлында уңышлар сиңа, Илмир!

***P.S.*** *С.Сөләйманова исемендәге стипендиягә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студентлары* ***Айгөл Абдрахманова, Руфинә Габдрахманова, Светлана Гыйләҗева, Чулпан Гобәйдуллина****, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты студенты* ***Элнар Байназаров*** *та лаек булдылар. Чын күңелдән котлыйбыз! Алга таба да уңышлар телибез!*

• Яшьлек-яңарыш

# «Безнең яшьлек мәңге сүнмәс ялкын...»

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Ел саен бөтендөнья яшьләре үзләренең бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр. 12 август – Халыкара яшьләр көне, 27 июнь – Россиядә яшьләр көне, 10 ноябрь – Бөтендөнья яшьләр көне. Соңгысы Лондонда барлыкка килгән.

Бирәдә 1945 елның 29 октябреннән 10 ноябренә кадәр яшьләр конференциясе уздырыла, анда 63 милләтнең 30 миллионнан артык яшьләре катнаша. Шул елдан башлап, 10 ноябрьдә Бөтендөнья яшьләр көне билгеләп үтелә. Быел да 11 ноябрь көнне М.Җәлил музей-фатирында Бөтендөнья яшьләр көне уңаеннан очрашу узды. Бу очрашуның төп максаты – яшь буынны республикабызның талантлы яшьләре белән таныштыру, аларны әдәбиятка, сәнгатькә тарту.

Яшьләр булган җирдә уен-көлке, шаушу, җыр-моң. Яшьлегендә Муса Җәлил дә шат күңелле, уен-көлке белән мавыгучан, музыка-җыр түгәрәкләренең үзәгендә йөрүче студент була. Муса җыр-музыка белән генә чикләнми, төрле кичәләрдә үз шигырьләрен дә укый. Һәм бүген дә шагыйрь яшәгән йортта шундый яшьләрнең булуы – табигый күренеш. Шуңа күрә очрашу кунаклары итеп, республикабызның талантлы шәхесләре: Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, сәнгать институты аспиранты Гөлнара Хәйруллина, шагыйрь Булат Ибраһимов һәм, бу талантлы яшьләрне табып, барлап һәм озак еллар алар белән эшләүче остаз – Татарстан Республикасының халык артисты Миңгол Галиев чакырылган иде.

Гадәттә, яшьләр булган бер кичә дә уен-көлкесез, җыр-моңсыз узмый. Замананда М.Җәлил дә шигърият һәм музыка кичәләре, иҗади очрашулар оештыра, радиотапшырулар әзерли. Талантлы яшьләрне халыкка таныту өлкәсендә бик күп эшләр башкара. Чыннан да, яшьлек – кеше гомеренең хисләр дулкынында кайнаган, хыял канатларында югарыга күтәрелгән иң матур чагы. Бу очрашуда да талантлы яшьләребез үз уй-фикерләре, тормышка карашлары турында сөйләп үттеләр. Еллар буе туплап барган тәҗрибәләре, киңәшләре белән студентлар, укучылар белән уртаклаштылар.

Соңгы елларда талантлы яшьләребезне үстерүгә республикабыз зур өлеш кертә, мөмкинлекләр тудыра. Яшьләрнең күбесе сәхнәгә тартыла. Җырчыларның күп булуы аркасында, кайберләре бер җыр белән генә популярлык казанып, сәхнәдән төшеп тә кала. Татар эстрадасында танылу алган җырчыларны укыткан остаз Миңгол абый Галиев: «Һәр кеше җырлый ала, теләк кенә кирәк», – дип белдерде.

Яшьлек турында кайсы гына шагыйрь шигырь язмаган да, кайсы гына язучы үз әсәрләрендә ул чорны сагынып искә алмаган? Муса Җәлилнең утызынчы елларда язган «Яшьлек» шигырендә дә бу рәхәт вакытның кадерен белеп яшәргә кирәклеге турында искәртеп үтелә. Чыннан да, бу матур вакытның кадерен белеп, яшьлегебезне гомергә истәә калырлык итеп, мәгънәле, файдалы үткәрергә кирәк.

• Белми калма!

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәптән тыш эшләр үзәге ТР Саба муниципаль районы балалар иҗат үзәге белән берлектә **Ш.Биктимеров исемендәге III ачык балалар театр сәнгате конкурсы уздыра**. Конкурсның максаты: балалар милли театрның иҗади үсешенә этәргеч бирү. Конкурста Татарстан районнарыннан 6-7 яшьлек балалар театр коллективлары катнаша. Алар 1-4, 5-7, 8-11 сыйныф төркемнәренә бүленәләр. Конкурска күренекле татар драматургы Туфан Миңнуллин әсәрләренә куелган спектакль тәкъдим ителүе шарт. Ике этапта уздырылачак конкурсның сайлап алу туры 10-21 ноябрь көннәрендә үткәрелә. Конкурсны йомгаклау 6 декабрь көнне булачак. Тулырак мәгълүматны 8 (84362) 2-33-89 телефонына шалтыратып белергә мөмкин.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.